ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының беренче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының беренче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2024 елгы көзге сессиясе эшче органнары турында.
2. Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларның нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе мәгълүматы.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисен сайлау турында.
4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарларын сайлау турында.
5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретарен сайлау турында.
6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларын төзү турында.
7. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларын сайлау турында.
8. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары рәисләрен сайлау турында.
9. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумын сайлау турында.
10. Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендәге текстлары тәңгәллеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясен төзү турында.
11. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты этикасы кагыйдәләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясен төзү турында.
12. Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла

торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясен төзү турында.

13. Профессиональ даими нигездә эшләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау турында.

14. Россия Федерациясе сенаторы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан вәкил вәкаләтләрен бирү турында.

15. Федераль телерадиотапшырулар конкурсы комиссиясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле турында.

16. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карап бетерелмәгән закон проектлары һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы норматив хокукый актлары проектлары буенча җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җаваплы комитетларын билгеләү турында.

17. Россия Федерациясе сенаторы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан вәкил вәкаләтләре бирелгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 13 сентябре
№ 2610-VI ДС